КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге составына керүче Завод Нырты торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

09.11.2020 № 2

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 25 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2020 елның 09 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2021 нче елда Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге составына керүче Завод Нырты торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Завод Нырты авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (таш ташу, таш сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 75 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 39 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 39 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге составына керүче Завод Нырты торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип таныргa.

2. «2021 нче елда Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге составына керүче Завод Нырты торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Завод Нырты авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (таш ташу, таш сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/nirti адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Олы Нырты авыл
җирлеге башлыгы Р.З.Сафаргалиев